

Кочкурово районы «Орбита» балалар сәламәтләндерv лагеры базасында «Яшә, туган тел!» җәйге тобәкара этномәдәни ял лагерендә Мәскәv, Оренбург, Пенза олкәләреннән, Мордовия, Татарстан республикаларыннан торле-торле конкурсларда, предмет олимпиадаларында урыннар яулаган укучылар 28нче июньнән 11нче июльгә кадәр ял иттеләр.
Традиция буенча ул мокша, әрзә һәм татар телләре буенча олимпиадаларда җинvчеләрне һәм призерларны, шулай ук башка этномәдәни конкурсларда катнашучыларны җыя.       Ике атна дәвамында туган тел буенча олимпиадаларда җинvче балалар актив ял иттеләр. Смена программасы белем бирv һәм кvнел ачу чаралары белән тулы иде. Ябылу тантанасында Мордовия Республикасында бала хокуклары буенча вәкаләтле (уполномоченная по правам ребенка в Республике Мордовия) Наталья Евгеньевна Юткина катнашты. Ул балаларны сменанын тәмамлануы белән котлады, аларнын казанышларын билгеләп vтте һәм алга таба да унышлар теләде. Шулай ук чарада Мордовия Моселман яшьләре берлеге рәисе Динара



Наиль кызы Шабаева «Рухи-мәдәни vзәк» һәм «Якташлар» исеменнән катнашучыларны

котлады һәм аларга истәлекле бvләкләр тапшырды. Кунаклар арасында Мордовия мәгариф министрлыгы белгече Надежда Васильевна Салмова, Саранск мәгариф vзәге этномәдәни бvлек модире Мария Михайловна Вельмакина иделәр. Алар да бу чарага vз



олешләрен кертеп, актив ял итvчеләргә дипломнар тапшырдылар.
Мордовия республикасы мәгариф министрлыгы карамагында сәләтле балалар очен ике дистәгә якын «Яшә, туган тел!» этномәдәни регионара ял лагере эшләv дәверендә лагерьне Мордовиянен атказанган укытычысы, М.П.Девятаев исемендәге «Высота» дигән Саранск шәһәре №15 мәктәп педагогы Марина Николаевна Миронова унышлы житәкли. Быел да балалар анын житәкчелегендә рәхәтләнеп ял иттеләр.
Мондый сменалар балалар тормышында моһим роль уйный, алар туган тел буенча белемнәрен тирәнәйтv генә тvгел, ә актив ял итv, яна дуслар табу һәм vзләрен зур, тату гаиләнен бер олеше итеп хис итv очен уникаль момкинлек бирә. Тагы биредә уеннар, биюләр һәм жырлар аша балалар Мордовия халкынын телен, мәдәниятен тирәнрәк анлыйлар. Балалар белән эшләv лагерьда унай атмосфера тудыру, кызыклы ял оештыру гына тvгел, ә моһим тормыш ориентирларын тапшыру, аларнын жылы һәм шатлык-лы истәлекләренен бер олеше булу момкинлеген бирә. Үсеп килvче буынны тәрбияләvгә коч кую - безнен киләчәгебезгә зур олеш кертv дигән сvз, чонки нәкъ менә шушы кызлар-егетләр иртәгәсе кон доньясын тозиячәк.



Татар группасы белән унышлы унбер ел Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы, “Педагог13.ру” vзәге методисты Фазия Фәрит кызы Боярова эшли.  Балаларнын ялы ничегрәк vтvе турындагы әнгәмәдә ул:
- Ике атна дәвамында балалар очен Н.П.Огарев исемендәге университет педагоглары мастер-класслар, Степан Эрьзя исемен йорткән музей, Ичалки педагогия колледжы хезмәткәрләре тарафыннан һәм СВОда катнашучылар - “Мирон” кушаматлы һәм тәмле

ашалар белән сыйлаучы “Бабка” белән кызыклы очрашулар оештырылды. Ял итvче һәр бала аларга рус, мукшы, татар телендә язган хатларын, адресатларга житкерсеннәр дип, матур теләр белән тапшырдылар. Тагы спидвей буенча Халыкара чемпионы Максим Захаров белән дә очрашу vтте. Ул балаларга бик кvп спорт бvләкләре таапшырды.



Кон саен тел интенсивлары vткә-релде, анда балалар мордва (мокша, эрзя) һәм татар халыкларынын мәдәнияте һәм традицияләре белән таныштылар. Татар теле интенсивынын нәтижәсе булып 9 июльдә балалар очен «Сабантуй» татар бәйрәме vтте. Бу бәйрәмдә кvнелсезлеккә урын юк иде, һәр кеше кvнеленә хуш килгән шогыль тапты. Ә башка милләт катнашучыларына «Сабантуй» бәйрәме тарихы турында кvбрәк белv кызыклы булды. Ярты кон дәвамында балалар торле ярышларда катнаштылар: билбау корәше, кул корәше, капчыкларда йогерv, мендәрләр белән корәш. Бәйрәм ярышлары жыр-бию белән vрелеп барды. Ә безнен кызларыбыз коянтә белән тулы чиләк суны подиумда шикелле алып килделәр. Нәтижәдә «Сабантуй» батыры – Карабанов Салават,



Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе 8 сыйныф укучысы; кул корәшендә малайлар арасында шул ук мәктәп укучысы Зульфат Тимкаев, ә кызлар арасында - Анна Ацапкина; коянтә белән суны ташу буенча ин унганы - Саранск шәһәре 39 мәктәп укучысы Мирослава Мысенко; капчык белән сугышта Саранск шәһәре 36 мәктәп укучысы Федотов Александр иде. Бәйрәмдә ин активлар – Лысова Ксюша, Назар Биккинин һәм башкалар иде.

Әлбәттә, «Яшә, туган тел!» милләтләр дуслыгы лагерендә ин кызыклы вакыйга – «Патша тоне» булды: тоне буе биергә һәм кvнел ачарга момкинчелек тудырылды, чонки иртәгә аерылышырга һәм яна жәйне котәргә туры киләчәк.

Алда әле балаларнын тагын актив ялы бар. «Орбита»да сәләтле балалар очен оештырылган этномәдәни лагерендә ял итvчеләр туган якларын, анын тарихын тирәнтен vзләштереп, ойләренә сәламәтлекләрен ныгытып, мәдәни баеп, кvп кенә дуслар булдырып кайттылар. Яна уку елына яна коч белән белем югарылыкларын яуларга әзерләнәләр алар.

**Наилә НАСЫРОВА**